Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Нырты авыл җирлеге Советы

# КАРАР

14 август, 2024 ел №20

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Нырты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Нырты авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган, түбәндәге нигезләр буенча түләп бетерү һәм (яисә) түләтү мөмкин булмаган җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч түләтүгә өметсез дип таныла:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән алып бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта, вафат булган яисә вафат булган дип игълан ителгән физик затларның бурычы булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган җирле салымнар буенча оешмалар яисә шәхси эшмәкәрләр карамагындагы бурыч булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганда, физик затларның 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуны раслый торган документлар булып түбәндәгеләр тора:

1) әлеге карарның 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органыннан бирелгән бурыч суммасы турында белешмә;

б) физик затның вафат булуына бәйле рәвештә салым органнарында исәптән төшерелүе турында белешмәләр;

в) мирас алуга хокук турында таныклык бирү турында белешмәләрнең булмавы хакында салым органы биргән белешмә;

2) әлеге карарның 1 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) оешманы, шәхси эшмәкәрне, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физик затны исәпкә алу урыны буенча салым органы биргән бурыч суммасы турында белешмә;

б) салым юкка чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында белешмәләр;

3) әлеге карарның 1 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

- 500 сумнан артмаган бурыч булу турында салым органы биргән белешмә.

3. «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге Советының 2023 елның 27 февралендәге 2 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авылы территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Нырты авыл җирлеге башлыгы Т.А.Котдусов